**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

12.12.2018 ел Иске Абдул авылы № 20

«Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендәге 37/20, 37/21, 37/22 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районының Иске Абдул авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчасын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Иске Абдул авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина